КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 30 июль г.Казань № 615

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 ел, 20 ноябрь, 887 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының район үзәкләреннән 11 километрдан ераграк урнашкан Татарстан Республикасының ерак булган һәм халык аз яши торган авыл пунктларына беренче дәрәҗәдәге кирәкле товарларны илтүгә бәйле булган кулланучылар кооперациясе оешмалары чыгымнарының бер өлешен каплау өчен Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләре бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибенә үзгәреш кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының район үзәкләреннән 11 километрдан ераграк урнашкан Татарстан Республикасының ерак булган һәм халык аз яши торган авыл пунктларына беренче дәрәҗәдәге кирәкле товарларны илтүгә бәйле булган кулланучылар кооперациясе оешмалары чыгымнарының бер өлешен каплау өчен Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләре бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибен раслау турында» 2017 ел, 20 ноябрь, 887 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының район үзәкләреннән 11 километрдан ераграк урнашкан Татарстан Республикасының ерак булган һәм халык аз яши торган авыл пунктларына беренче дәрәҗәдәге кирәкле товарларны

илтүгә бәйле булган кулланучылар кооперациясе оешмалары чыгымнарының бер өлешен каплау өчен Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләре бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешне кертергә:

5 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Башка бюджетара трансфертларны алучыларга башка бюджетара трансфертларны бүлү Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты белән раслана.

Татарстан Республикасының муниципаль берәмлеге бюджетына бирелә торган башка бюджетара трансфертлар күләме түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$С = \frac{Р \times Н \times (100 + К_1) \times Ц}{100},$$

монда:

С – башка бюджетара трансфертлар күләме, сум;

Р – Татарстан Республикасының район үзәкләреннән 11 километрдан ераграк урнашкан Татарстан Республикасының ерак булган һәм халык аз яши торган авыл пунктларына беренче дәрәҗәдәге кирәкле товарларны илтү өчен файдаланылган транспорт чараларының планлаштырыла торган илтүләр саныннан чыгып исәпләнә торган һәм көтелә торган йөрү юлы, чакрым;

Н – Россия Федерациясе Транспорт министрлыгының «Автомобиль транспортында ягулыклар һәм майлау материаллары чыгымы нормалары» методик тәкъдимнамәләрен гамәлгә кертү турында» 2008 елның 14 мартындагы АМ-23-р номерлы боерыгы нигезендә ягулык чыгымының база нормасы, 100 километрга литр;

$К_1$ – Россия Федерациясе Транспорт министрлыгының «Автомобиль транспортында ягулыклар һәм майлау материаллары чыгымы нормалары» методик тәкъдимнамәләрен гамәлгә кертү турында» 2008 елның 14 мартындагы АМ-23-р номерлы боерыгы нигезендә елның кышкы көннәрендә автотранспортны эшләтү өчен ягулык чыгымының база нормасын күтәрү коэффициенты, процент;

Ц – башка бюджетара трансфертларны бүлгән вакытта Татарстан Республикасының муниципаль берәмлегендә ягулык-майлау материалына базар бәясе, 1 литрга сум.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин